ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт,
Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 04 » март 2021 ел № 5

**Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» башкарма комитетының карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.“Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында” Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 11 августендәге 15 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Белешмә (өземтә) бирү буенча электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын нигезләмәләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә расланган электрон формада дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүгә күчү план-графигы белән билгеләнгән срокларда кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИШИТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ